КҮЗ ТИМӘСЕН!

Татарстандагы төрле дин һәм милләт вәкилләренең дус-тату яшәвенең сере нидә?

> 2

КАЗАННАН – ЙОЛДЫЗЛАРГА

КФУ астрономия обсерваторияләренең ЮНЕСКО исемлегенә керүенең әһәмияте нәрсәдә?

> 2

ХАЛЫКНЫ УЙЛАП

Киләсе елда социаль тармакта үзгәрешләр көтелә

> 3

ҮЗ ҖИРЕМ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 192 (29159) | Чәршәмбе | 27 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БӘЙРӘМ БУЛМАСЫН БӘЛА

Анна Арахамия

Сак бул!

Бәйрәм яме китмәсен, яхшы кәеф төшмәсен өчен, нишләргә? Уяулыкны югалтмаска, билгеле. Барыбыз да белгән, шулай да, елларга алданып, онытырга мөмкин кагыйдәләр турында искә төшерделәр.

Иминлек сагында

Бәйрәмнең асыл ямен ул-бу хәлләр ала. Аеруча янгын очраклары арта. Статистика да шуны сөйли: Яңа ел ялында янгыннар саны уртача – 20, ә үлем очраклары 50 процентка арта.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Максим Трущин әйтүенчә, быел республикада 4821 янгын очрагы теркәлгән. Быелтыр 4913 иде. Әмма очраклар кимесә дә, ялкын тelләре аркасында гомерләре өзелгәннәр саны арткан. 11 процентка!

– Янгыннарда 134 кеше үлде, 199 кеше төрле дәрәҗәдә зыян күрде, – диде Максим Трущин.

Янгынга китергән сәбәпләр нинди соң? Иң элек – ут белән саксыз эш итү. Яңа ел ялы вакытында булган янгыннарның (2022–2023 еллар) гомуми санының 40 проценты шуңа туры килә. Аннан кала электр җиһазларын куллану кагыйдәләрен бозу (27 процент), җылыту мичләренең һәм төтен чыгару урыннарының дөрес итеп урнаштырылмавы аркасында (24 процент). Хәмер хәкемендә булганнарда – янгын сәбәпчеләре. Шундый 12 янгын очрагы булган, ялкын 5 кешенең гомерен өзгән.

Максим Трущин хәбәр иткәнчә, 29 декабрьдән алып киләсе елның 9 гыйнварына кадәр Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләре көчәйтелгән режимда эшләячәк. Тәүлек әйләнәсе 2200 кешенең кизү торуы, 1100 берәмлек техника җәлеп ителүе күздә тотыла.

Гадәттән тыш хәлләр була калса, 01 яки 101, 291-91-91 номерларына шалтыратыра.

Чисталык сагында

Ял иткәндә, күп йөрелер, билгеле. Җәяүлеләргә дә, «тимер ат»ын иярләгән кешеләргә дә рәхәт булсын өчен, юлларның чисталыгы кирәк. Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов, чисталык тәэмин ителәчәк, дип вәгъдә итте. Юлдагы тәртипне 1136 берәмлек техника тәэмин итәчәк, 100 мең тонна ком кушылмасы әзерләнгән (20–25 проценты кулланылган, ди инде).

Эш тә, куаныч та өстән, шушы көннәрдә кары да мулдан ява. Көчле явым-төшемнәргә әзерме без?

Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен штраф	
Гражданнарга	10–20 мең сум
Вазыйфаи затларга	30–60 мең сум
Юридик затларга	400–800 мең сум
Юридик зат булмыйча эшмәкәрлек итүче затларга	60–80 мең сум

– Шөкер, кар ява башлады. Көтеп алдык бу карны, ниһаять, елгаларыбыз су белән тулыр, – ди Фәрит Хәнифов. – Юллар чистартылып тора. Техникасы да җитәрлек. Әйтик, дүшәмбе яуган карны чистарту өчен 700–800 техника эшкә чыкты. Тозын да, комын да сибәбез. Кар яуганда түгел, билгеле, чөнки ул юлларда «ботка» гына ясый. Метеостанцияләр эшләп тора. Метеостанция ярдәмендә берничә көн алдан һава торышына фараз алабыз.

ЯРАМЫЙ	МӨҺИМ
Махсуслашмаган урыннардан («танышлар», базар) пиротехника, фейерверклар сатып алу.	Пиротехника, фейерверкларны бары тик махсуслашкан кибетләрдән алырга.
Товар билгесе, сертификаты булмаган, упаковкасы бозылган, юешләнгән, киселгән әйберләр сатып алу.	Пиротехникага бәйле документларны сорарга.
Җитештерү вакытына игътибар итмәү.	Инструкция, җитештерү вакытына игътибар итәргә.
Пиротехниканы кесәдә, автомобильдә, кояш нурлары тиз үтеп керә торган җирдә саклау.	Фейерверкларны коры урында, балалардан ерак урында сакларга.

Саллы ярдәм

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өчен, республикада 2024 елда – 37,7 миллиард сумнан артыграк, 2025 елда 40 миллиард сум чамасы тотылачак. Хөкүмәт карарыннан күренгәнчә, ике елга бу максатка барлыгы 77,69 миллиард сум каралган.

Бу акча федераль һәм республика казнасыннан бирелә. Алдагы елларда шулай ук Пенсия фондыннан, ул үзгәреп корылгач – Пенсия һәм социаль иминият фондыннан, бюджеттан тыш чыганаклардан субсидияләр җибәрелгән.

Акча социаль түләүләргә, өлкәннәрнең тормышын, гаиләләрнең матди хәлен яхшырту, социаль хезмәт күрсәтүне үстерү, кереме яшәү минимумыннан кимрәк булганнарның санын киметүгә тотыла.

Артыграк җыйганнар

315 миллиард сум. Федераль бюджетка компанияләрнең чиктән тыш зур табышына салымнан әлегә шуның кадәр акча кергән. Россия финанс министры Антон Силуанов әйтүенчә, башта ел йомгаклары буенча 300 миллиард сум җыю күздә тотылган булган. Министр сүзләренә караганда, компанияләрнең күпчелеге салымны вакытыннан алда 5 процентлы ставка буенча түләгән.

Исегезгә төшерәбез: чиктән тыш зур табышка салым 2021–2022 елларда табышы уртача 1 миллиард сумнан арткан компанияләргә кагыла. Аның ставкасы – 2021–2022 еллардагы табыш белән аннан алдагы еллардагы табыш арасындагы аерманың 10 проценты күләмендә. Компанияләр салымны 2024 елның 28 гыйнварына кадәр түләргә тиеш. Шул ук вакытта агымдагы елның 30 ноябренә кадәр түләнгән очракта, процент ставкасы ике тапкыр кими.

Саулыктан аермасын

Татарстанда шикәр чиреннән интегүче балалар саны елдан-ел арта. Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар буенча баш эндокринологы Мария Шайдуллина әйтүенчә, 2014 елда мондый авырулы 750 малай-кыз учетта торган булса, бүген аларның саны – 1,5 мең. Ягъни 10 ел эчендә шикәр чире белән авыручы балалар ике тапкыр күбәйгән.

Белгеч билгеләп үткәнчә, балаларда, бигрәк тә нәниләрдә шикәр чирен ачыклау авыр. Еш сусау, кече йомыш белән еш бәдрәфкә йөрүе, әйбәт ашавына карамастанябыгуы, тәнендәге яраларының озак төзәлүе, хәлсезлеге ата-ананы сагайтырга тиеш. Мондыйлар, гадәттә, мәктәптән яки балалар бакчасыннан кайткач, спорт секцияләреннән, түгәрәкләрдән баш тартып, ятып торуны хуп күрә. Шул ук вакытта бала сәеррәк (тиранрәк, сиргәрәк) сулыш ала, авызыннан ацетон исе килә.

Сайлау

Әзерлек башланды

Татарстанда сайлауга гаилә белән йөрү матур гадәткә әйләнде. Бу – республиканы башка төбәкләрдән аерып тора торган иң төп үзенчәлекләрнең берсе. Татарстанның Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев журналистлар белән очрашуда шулай дип белдерде.

– Без киләсе елда узачак сайлауга әзерләнә башладык инде. Алда җаваплы һәм мөһим эшләр көтә. Мартта – Россия Президентын сайлау, сентябрьдә Татарстан Дәүләт Советына сайлаулар узачак. Тупланган тәҗрибә, барлык дәрәҗәдәге сайлау комиссиясе хезмәткәрләренең осталыгы ярдәмендә бу эшне җиренә җиткереп башкарырбыз дип өметләнәм, – ди Андрей Кондратьев. – Татарстанда яшәүчеләр сайлауда актив тавыш бирә. Моны рәсми саннар да раслый. Сайлауга гаиләләре белән йөрүчеләр күп. Татарстанны башка төбәкләрдән аерып тора торган иң төп үзенчәлекләрнең берсе бу. Киләсе ел Гаилә елы дип игълан ителгәнлектән, Үзәк сайлау комиссиясе «Гаилә белән сайлауга» дип исемләнгән проектны да тормышка ашырачак.

Билгеле булганча, 7 декабрьдә Федерация Советы Россия Президентын сайлау көнен раслады. Төп тавыш бирү 17 декабрьдә узачак. Илнең Үзәк сайлау комиссиясе карары белән киләсе елгы сайлаулар өч көн – 15, 16 һәм 17 март көннәрендә узачак.

– Өч көнлек тавыш бирү форматы безгә бик уңайлы, гадәти. Беренче тапкыр аны коронавирус арасында кертелгән пандемия шартларында кулланып карадык. Элегрәк моны санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне үтәү максатыннан эшләсәк, хәзер өч көнлек тавыш бирү тәртибе сайлаучыга уңайлы булсын өчен кертелә, – ди Андрей Кондратьев.

Халык арасында уздырылган сораштыру да бу карарның дөрес булуын күрсәткән. Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге тарафыннан уздырылган соңгы тикшеренү барышында респондентларның 74 проценты – сайлауның өч көн узуын хуплавын, 15 проценты моңа тискәре каравын белдергән.

Ил Президентын сайлау көннәрендә Татарстанда 2727 сайлау участогы, 21 меңнән артык участок сайлау комиссиясе хезмәткәре, Үзәк сайлау комиссиясеннән 14 вәкил эшләячәк. 45 вакытлыча сайлау участогы да булачак. Алар хастаханә, ял йортларында, тикшерү изоляторларында, «Казан» халыкара аэропорты һәм «Казан-1» тимер юл вокзалы бинасында эшләячәк.

Сүзгә-сүз

Роман ЛИЗАЛИН, «Татарстан флоты» генераль директоры:

Транспорт куркынычсызлыгы, логистика һәм икътисадый яктан караганда, озын су юллары була торып, аларны кулланмау бер дә дөрес түгел. Безнең ил бу яктан бик отышлы: бездә, мөгаен, дөньядагы иң яхшы елгалардыр. Татарстанга аеруча бәхет елмайды: без ике зур елга – Идел һәм Кама кушылган урында торабыз. Безнең аша Нократ һәм Зөя үтә. Без аларны кулланырга тиеш.

(«Татарстан 24» каналына биргән әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ГАИЛӘ

38,4 млн	>>	гаилә
16,5 млн	>>	12 кешелек гаилә
10,3 млн	>>	3 кешелек гаилә
7,0 млн	>>	4 кешелек гаилә
4,6 млн	>>	5+ кешелек гаилә

*Росстат мәгълүматлары нигезендә

Яңа елга җепшетә

Узган атнадагы аномаль җылы һавадан соң Татарстанда берникадәр суытты. Яңа ел алдыннан тагын җылыта.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, җомга – 29 декабрьдә аз гына кар явачак һәм тагын да салкынайтачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –5…–10, төнге сәгатьләрдә –9…–14 күрсәтәчәк, урыны белән –17 градуска кадәр төшәчәк.

Шимбә – 30 декабрьдә, республикага чираттагы циклон үтеп керү сәбәпле, юеш кар явачак. Көндез җылыта: һава температурасы 0…–5 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Белгечләр әйтүенчә, декабрьнең соңгы декадасында Татарстанда уртача температура нормадан югарырак булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФЕТНӘ БАР, ӘММА РЕВОЛЮЦИЯ ТҮГЕЛ

Дөньякүләм икътисадый һәм сәяси кризис билгеләре әле бер урында, әле икенче җирдә аваз бирә. Сайлауда халык яклавы нәтиҗәсендә җиңеп чыккан Аргентина Президенты Хавьер Милейның беренче адымнарыннан ук кешеләр риза түгел. Илдә дәвамлы һәм ахыры күренми торган протест акцияләре бара. Милей фетнәне көсәкләр ярдәмендә бастырырга омтыла. Кытай Аргентинага валюта кредитлары бирүне туктатты, чөнки Милей үзе коммунистлар белән араны өзәргә вәгъдә иткән иде. Сайлаудан соң ул, вәгъдәсен онытып, алар белән хезмәттәшлек итмәкче булып карады, ләкин Азия гиганты аның сайлау алды кампаниясендәге үз-үзен тотышыннан канәгать булмавын бик тиз күрсәтте. Яңа Президент аргентиналыларның күңеленә бер дә хуш килми, чөнки илдә болай да киеренке булган хәлне тагын да кискенләштерде.

Европа иле Сербиядә исә 17 декабрьдә парламент һәм җирле советларга сайлаулар булып узган иде. Сайлауда гамәлдәге Президент Вучич партиясе җиңде. Оппозиция сайлау нәтиҗәләреннән риза булмады. Тавышлар урланды, сайлау нәтиҗәләре дөрес күрсәтелмәде, диган сылтау белән урамга чыкты. Халыкара күзәтүчеләр дә серб сайлавын дөрес үткәрелмәде дип игълан итте. Бу атна башында Белградта хәл кискенләште. Дүшәмбе көнне Үзидарә министрлыгы каршына (анда шундый министрлык та бар икән) йөзләгән студент җыелды. Алар сайлаучылар исемлеген кабат тикшерүне таләп итте. Фетнәчеләр, исемлектә «фантом сайлаучылар» күп иде, дип бара. Министрлык исә моны, уйлап чыгарылган нәрсә, ди. Дүшәмбедә протестта катнашучы 38 кеше кулга алынды. 8 полиция хезмәткәре яраланды, диделәр. Ратуша бинасының тәрәзәләре ватылды. Фетнәчеләр бинаны штурмладылар. Вучич авышлыны рәвештә халыкка мөрәҗәгать белән чыкты. «Гражданнарны борчылмаска өндим, – диде ул. – Сүз революция турында бармый. Хокук саклау органнары вазгыятьне контрольдә тота».

Серб прогрессив партиясе парламент сайлавында 47 проценттан артыграк тавыш җыйган. Белград шәһәр советына сайлауда СПП шулай ук иң күп тавыш алган, әмма идарә итүче коалиция формальләштырылык ук түгел. Оппозиция бигрәк тә Белград идарәсенә сайлау нәтиҗәләреннән риза түгел. Провинцияләрдә идарә итүче партияне ихлас яклаган халыкны башкалага алып килеп тавыш бирдерттеләр, дигән фикерне алга сөрәләр.

Сербия Россиянең Европадагы аркадашы санала. Кремль табигый рәвештә Вучич һәм аның партиясен яклый. Әмма БМОда тавыш биргәндә Сербия вәкиле Россияне агрессор буларак таныган иде.

Россиядә

ДУСЛЫК КАДЕРЕ

Санкт-Петербургта 25 декабрьдә Югары Евразия икътисадый советының утырышы ачылды. Бу халыкара оешма элекке совет республикаларыннан тора. Әрмәнстан, Беларусь Республикасы, Кыргызстан, Казахстан һәм Россия – аның төп әгъзалары, Үзбәкстан һәм Молдова күзәтүчеләр сыйфатында катнаша. Аларга тагын Куба да килеп өстәлде. Киләчәктә оешманың киңәю потенциалы бар, чөнки Иран, Вьетнам, Сингапур һәм Сербия советның ирекле сәүдә зонасына керәләр. Тагын берничә ил белән сөйләшүләр бара. Көнбатыш санкцияләре югарыда саналган илләр белән хезмәттәшлекнең әһәмиятен арттырды, чөнки дус илләрдән башка Россия икътисады Көнбатыш басымына каршы тора алмас иде.

25 декабрь – безнең өчен символик дата. Моннан 32 ел элек нәкъ шул көнне СССР Президенты Михаил Горбачев вазыйфасыннан китте. Халыкка отставкасы турында игълан итте. Дөньядагы иң куәтле ике державаның берсе булган ил үзенең соңгы сәгатьләрен кичерә иде. Шуннан соң ун минут вакыт үткәч, маршал Шапошников Горбачев кулыннан атом-төш корабы белән идарә итү кодлары язылган чемоданны кабул итеп алды. Бер көннән соң СССР яшәүдән туктады. Хәзер без шул чакта ясалган адымнар нәтиҗәсендә барлыкка килгән фаҗигане кичерәбез. Шунысы кызык: элекке союздаш республикалар халкы арасында һаман да үзләрен безнең белән уртак илдә яшибез дип санаучылар байтак. Күптән түгел генә бу илләр авторының танышы Кыргызстанга барып кайтты. Бишкек аэропортында Казанга очучы самолетка регистрация көтеп утырганда, яшь кенә бер кыргыз егете, килеп, аннан Казанга шушы терминалдан утырыргамы икәнен сораган. Казанга очучылар арасында күпчелек индуслар икән. Уңай җавап алгач, кыргыз, маңгаен сөртеп, татар егетенә: «Безнекеләрдән бары тик син генә, калганнар барысы да – чит ил кешеләре», – дип зарланган.

Мәскәү хәзер элекке ватандашларның әһәмиятен яхшы аңлый. Үзбәкстаннан шундый хәбәр алынды: «Үзбәкстанның 18 яшьтән өлкән барлык гражданнары Сәмаркандта IT белгечлеккә бушлай укый ала: анда Россиянең «Сбер School 21» дип аталган программалаштыру мәктәбе ачылган». Көнбатыш дәүләтләре Урта Азияне Россия йогынтысыннан тартып алу өчен көрәш алып бара. Рәсми сәясәтчеләре Урта Азиядән кайтып керми диярлек. Төбәктәге Кытай йогынтысы турында әйтеп тә тормыйк инде.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ЕГЕТ ЯУДА БЕЛЕНЕР

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашучы, Россия Герое Айнур Сафиуллин белән очрашты. Республика башлыгы якташыбызны лаеклы бүләк алуы белән котлады.

Хөкүмәт йортында узган очрашуда Россия Героеның әти-әнисе һәм хатыны Дарья да катнашты. Билгеле булганча, гвардия капитаны Айнур Сафиуллинга Россия Герое исемен 19 декабрьдә Россия Президенты Владимир Путин тапшырды. Бу көнне махсус хәрби операциядә катнашучы 8 кеше Илбашы кулыннан бүләк алды.

Алдан хәбәр итүләренчә, Айнур Сафиуллин штурмлау отряды белән торак пунктны азат итүдә катнашкан. Ул үз солдатлары белән өч сәгатьтән артык дошманның контрһөҗүмен тоткарлап торган һәм, шәхси составны югалтмыйча, куелган бурычны үтәгән. Һөҗүм барышында Айнур Сафиуллин яралана. Моңа да карамастан, аның тәвәккәллеге һәм дөрес карар-гамәлләре уңышка ирешергә ярдәм итә. Бәрелеш барышында дошманның икедән артык взводы юк ителә, сигез кеше әсирлеккә алына, Javelin һәм NLAW ракета комплекслары кулга төшерелә.

– Чын күңелдән котлыйбыз, егет! – диде Рөстәм Миңнеханов Россия Герое белән очрашуда.

Татарстан Рәисе Айнур Сафиуллинның хезмәте, аның киләчәккә планнары турында сорашты, алга таба уңышлар теләде. Әңгәмә барышында башка темаларны да күтәрделәр.

Айнур Сафиуллинның әтисе дә – сугыш хәрәкәтләре ветераны. Ул Әфганстанда хезмәт иткән.

– Бу хәлләрне фронтта күрдем, анда, әлбәттә, куркынычрак. Мин улым өчен шатмын, аны кеше һәм командир буларак хөрмәт итәм, – дип хис-кичерешләре белән уртаклашкан Альберт Сафиуллин.

tatarstan.ru

Нәтиҗә

МИЛЛИ ИГЕЛЕК

Безнең төп байлыгыбыз – милләтара, динара тынычлык һәм татулык. Татарстан Республикасы каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет белән Татарстан Республикасында милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыру буенча оештыру комитетының берләштерелгән утырышында республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде. Чарада узып баручы елга нәтиҗә ясап, киләсе елга бурычлар куелды.

– Республикада яшәүче һәр милләт вәкилен кайгырту – безнең бердәмлекнең нигезе. Кеше хокукларын саклауга, туган телләрне, мәдәниятләр һәм традицияләрне үстерүгә аеруча игътибар бирелә, – дип башлады сүзен Рөстәм Миңнеханов.

Рәис белдергәнчә, халыкның рухи ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен барлык шартлар да тудырылган, төрле программалар тормышка ашырыла. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Татарстан халкының 80 проценттан артыгы милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне уңай бәяли. «Шул ук вакытта Көнбатыш махсус хезмәтләренең безнең арада низаг булдыруның туктаусыз омтылышларын да күрәбез. Лидерыбыз Владимир Путин бу уңайдан динара һәм милләтара аерманың җәмгыятьне какшатыру юл куймаячагын әйтте», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис 2025 елга дәүләт милли сәясәте стратегиясен тормышка ашыру буенча зур эш башлануын әйтте. Татарстанның актив катнашуы тиешлеген дә ассызыклады. Монда фәнни бергәлек, Татарстан халыклары ассамблеясы, Рус милли-мәдәни берләшмәсе, Бөтендөнья татар конгрессы, Диния нәзарәтенең тәкъдимнәре кирәк. Рәис чыгышында милләтара мөнәсәбәтләргә, Татарстанда яшәүчеләрнең этномәдәни һәм рухи үсешенә ярдәм итүгә бәйле мәгълүмати яктырту мөһимлегенә дә басым ясады.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев исә милли сәясәтне яктыртуга бәйле эшчәнлек белән таныштырды.

– Безнең эш мәгълүмати яналарны фаразлау, ачыклау һәм бәяләү, фактларны һәм вакыйгаларны дөрес бәян итүгә, рухи-әхлакый кыйммәтләрне бигрәк тә яшьләр арасында ныгытуга юнәлдерелгән, – диде Айдар Сәлимгәрәев.

Мәдәният министрлыгы күпмилләтле халыкның бердәмлеге, милләтара татулыкка бәйле чарада катнашучыларны да санаган. Ирада Әюпова әйтүенчә, анда быел 185 меңнән артык кеше катнашкан. Бу узган елга караганда 35 процентка күбрәк. Милли бәйрәмнәрдә катнашучылар саны исә 1,5 мәртәбә арткан. Сүз уңаеннан, Казан дәүләт мәдәният институты Сабантуй үткәрү буенча режиссерлар өчен курслар оештырган. Әлеге курсларда республика районнарыннан җитмештән артык белгеч катнашкан.

– Милли бәйрәмнәр җанга рухи азык бирә. Алар аша без бер-беребезне яхшырак аңлый башлыйбыз. Шулай итеп, милләтара дуслык нык һәм илебездә бердәмлек хисе чыныга, – диде Ирада Әюпова.

Министр әйтүенчә, мәдәнияттә эшнең нәтиҗәсен икенче көнгә үк күреп булмый. Моны бары вакыт узгач кына күрергә мөмкин. Милли традицияләр һәм мәдәниятләр елының төп асылы – үзебезнең тамырларыбызны тану. Кем без? Каян килдек? Безнең тарихыбыз нинди? Нинди гореф-гадәтләребез бар – һәр кеше шуны аңласа иде. Шуңа күрә үзаңны формалаштыруга багышланган проектлар да булдырылган.

– Хәзер инде милли бизәкләр белән баетылган, элеккеге технологияләр кулланып эшләнгән аяк киемнәре, мендәр, намазлык, хәтта көнкүреш җиһазлары барлыкка килде. Бабаларыбыздан килгән һөнәрчелекне заманча тормышка җайлаштырып, саклап калу һәм киләчәк буынга тапшыру даими алып барыла торган эш булса да, быел мөһим нәтиҗәләргә килдек. Шулар арасында – Рәисебез тарафыннан һөнәрчелек үзәген булдыру турындагы карар, – диде Ирада Әюпова.

Балалар мәдәнияте темасы да читтә калмады. Министр бу мәсьәләдә кайбер районнарны активрак булырга чакырды. 2013 елдан бирле узылучы «Моңлы тамчы» балалар фольклор коллективы фестивалендә катнашучы төркемнәрнең ике мәртәбә артуы күңелле анысы. Ә менә Апас, Азнакай, Актаныш, Ютазы районнарыннан шушы еллар эчендә бер гариза да кермәгән.

Арча районында 33 төрле милләт вәкиле яши. Район башлыгы Илшат Нуриев та районда башкарылган эшләр турында сөйләп кенә калмыйча, тәкъдимен дә җиткерде.

– Күп еллардан бирле җыелган кыйммәтләрне кыска вакыт эчендә генә торгызып бетереп булмый. Ләкин эш нәтиҗәсе алга таба күренер. Бүген утырткан орлыклар шытып чыгып, үсенте бирерләр. Халыкның милли мәдәниятккә, сәнгатькә ихтыяҗын уяту беренче өлеш булса, икенчесе: бу ихтыяҗны канәгатьләндерү максатыннан тудырылган продуктлар фәнни яктан дәлилләнгән булырга тиеш. Татар калфагы икән, татар милли бизәге, татарларга хас булган төсләр белән бизәлергә тиеш. Русларның Май чабу йоласы икән, аны үзебезгә яраклаштырып түгел, ә нәкъ борынгыча киләчәк буынга тапшырырга кирәк дип саныйм. Бу очракта милли сәнгатьне, милли мәдәниятне тирәнтен өйрәнгән белгечләрнең ярдәме бик урынлы булыр иде. Әлеге мәсьәләне республика күләмендә аерым өйрәнүне тәкъдим итәм, – диде Илшат Нуриев.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯҢА ЕЛ АЛДЫННАН БҮЛӘК

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның төрле мәдәният оешмаларына яңа хезмәт автомобиле тапшыру тантанасында катнашты. Рәис, рәхмәтен белдереп:

– Мәдәният оешмаларының уңышлы эшләве нигезендә сез – үз эшләрегеннең осталары торасыз. Бу автомобильләр Яңа ел алдыннан сезгә кечкенә бүләк булсын, – диде. Барлыгы 50 автомобиль тапшырылды.

ЙОЛДЫЗЛЫ СӘГАТЬ

Мәдәни мирас

Дүртенче җиңү. Билгеле булганча, быел КФУның астрономия обсерваторияләре ЮНЕСКО бөтендөнья мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелде. Республика гына түгел, бөтен Россия өчен әһәмияткә ия вакыйга турында Татарстан Хөкүмәт йортында узган елның соңгы брифингында да сөйләштек.

Барыбыз өчен дә сөенечле карар ЮНЕСКО комитетының Согуд Гарәбстанында узган 45 нче сессиясе барышында кабул ителде. Шулай итеп, хәзер Татарстанда ЮНЕСКО исемлегенә кергән 4 объект бар. Алар – Казан Кремленең тарихи-архитектура комплексы (2000 ел), Болгар тарихи-археология комплексы (2014), Успение соборы белән Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыре (2017) һәм Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре (2023). Без – Россиядә бердәнбер. Россия Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова әнә шуңа басым ясады.

– Бер төбәктә берьюлы дүрт бөтендөнья мәдәни мирас объекты! Татарстанда яшәүчеләрне чираттагы зур җиңүебез белән ихластан котлыйм! Безнең өчен тамырларыбыз, тарихыбыз зур кыйммәткә һәм әһәмияткә ия. Шуңа да бу – безнең өчен мөһим җиңү. Кая гына барсак та, бездән: «Татарстанның бу мәсьәләдә бөтен планетадан алда баруның сере нидә?» – дип сорыйлар. Җавабы гади аның. Без тарихи мирасны саклау турында беренче ел гына кайгыртмыйбыз. ЮНЕСКО белән дә узган гасырның 90 нчы елларында ук хезмәттәшлек итә башладык, – дип сөйләде ул.

Сүз уңаеннан, КФУның астрономия обсерваторияләре – ЮНЕСКОның Россия исемлегендәге фәнгә бәйле беренче объект. Татьяна Ларионова сүзләре белән әйтсәк, без аларның дөнья күләмендә танылган зур фәнни ачышларда, чараларда уйнаган роле турында горурланып сөйли алабыз.

Билгеле, бу җиңүнең гадәти шартларда яуланмавын да искәртергә кирәк. Бүгенге сәяси вазгыятьтә Россиядә урнашкан чираттагы мәдәни объектны дөньякүләм мәдәни мирас итеп тану үзе үк әһәмияткә ия. Брифинг дәвамында бу фикер бер генә мәртәбә яңгырамады.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова обсерваторияләрнең исемлеккә кертелергә тиешлеген раслаганда туган кайбер сораулар турында сөйләде.

– Комиссия әгъзаларына мәгълүмати досьены тәкъдим иткәч, безгә берничә дәгъва белдерелде. Шуларның берсе – «Россия галимнәренең дөнья күләмендә танылмавы». Моның киресен раслау өчен, бик күп эзләндек һәм чын мәгънәсендә җитди дәлилләр тәкъдим иттек, – диде ул.

Аның сүзен КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры урынбасары, һәйкәлләр һәм истәлекле урыннарны саклау буенча халыкара советның (ИКОМОС) Россия комитеты вице-президенты Рафаэль Вәлиев дәвам итте. Әйтик, аның сөйләвенчә, обсерваторияләр турында 12 томлык проект әзерләргә туры килгән.

– Аларда без барлык сорауларга җавап әзерләдек, объектның универсаль кыйммәтен расладык. Комиссия тарафыннан дәгъвалар булып торды, әмма ахыр чиктә алар безне ишетте, татарларны болай гына җиңеп булмавын аңладылар, – дип сөйләде белгеч.

Киләчәктә обсерваторияләрне ни көтә соң? ЮНЕСКО исемлегенә кертелү мәдәни объектка абруй гына түгел, төбәккә җаваплылык та өсти. Журналистлар белән очрашуда катнашучыларның сүзләреннән аңлашылганча, андый төр объектларны саклау һәм тануның үз критерийлары, кагыйдәләре һәм үз чикләүләре бар. Әмма кайсы яктан карасаң да, мөмкинлекләре дә җитәрлек. Туризм буенча Дәүләт комитеты өчен бигрәк тә. Татьяна Ларионова моны гади генә мисалда раслады. «Әйтик, 2007 елда – Зөя утрау-шәһәрчеген ЮНЕСКО исемлегенә кертергә әзерләгәндә анда нибары 7 мең турист килгән. Узган елны бу сан 1 млн 100 меңгә җитте», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белешмә өчен

Обсерваторияләрнең берсе (Казанның Кремль урамында урнашкан) 1833–1837 елларда, икенчесе (Яшел Үзән районында урнашкан) 1899–1901 елларда төзелгән. Алар хәзергә кадәр үз билгеләнеше буенча кулланыла.

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШКАНДА

Яңа ел могҗизасы

«Теләкләр чыршысы» бөтенроссия акциясе балаларның хыялларын тормышка ашыруны дәвам иттерә. 8 яшьлек Варвара Василованыкы да чынга ашты. Кечкенә кызчыкны үзендә «ШАЯН ТВ» телеканалы кунак итте.

shayantv.ru

Варвара Кыш бабайдан Яңа елга балалар телеканалы студиясенә барасы һәм радиостанция белән танышасы килүе хакында язган. Тылсымлы чыршыдан аның хатын Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сафаров алган. Һәм, ниһаять, кызның күптән хыялланган теләге чынга ашты!

Бик актив һәм кызыксынучан кызны «ШАЯН ТВ» алып баручылары һәм хезмәткәрләре каршы алды. Аңа студия буенча экскурсия үткәрделәр, телеканалның проектлары, популяр тапшырулары, аларның алып баручылары һәм катнашучылары белән таныштырдылар. Нәни кунак, «Болгар радиосы» студиясенә кереп, радиостанция эшчәнлеге белән дә танышты.

– Монда килмәгебезне әнием миңа бүген генә әйтте. Мин бу сюрпризга бик гаҗәпләндем һәм шатландым. Хыялым чынга ашты. Мин мультфильмнар, кызыклы программалар карарга яратам. Хәзер инде «ШАЯН ТВ»да эшләргә хыялланам. Монда шундый кызык, – диде 8 яшьлек Варвара.

Варвара мәктәптә рәсем һәм математика дәресләрен ярата, музыка һәм йөзү белән мавыга. Әле хыялы исә – мультипликатор булу. Варвара дубляж студиясендә мультсериалларны тавышландыруның мавыктыргыч процессын да күзәтә алды. Үзен дә тавышландыручыролендә сынап карады.

Варвараның әнисе Олеся Василова кызының татар телен өйрәнергә хыяллануы турында әйтте.

– Әлеге акция турында мин күптән беләм, узган елларда никтер катнашырга уйламадык. Менә бер ел чамасы инде Варвара студиягә барырга теләвен әйтә килде. Ул телевизор карарга ярата, аңа балаларның тапшыруларда катнашуы бик ошый. Миңа: «Әни, мин дә анда төшәргә телим», – дия иде. Сәламәтлеге чикле булгач, минем өчен бу мөмкин түгел кебек тоелды. Мин аңа: «Кайчан да булса эләгербез», – дидем. Былел хат яздым, ләкин җавап килер дип һич көтмәгән идем. Безнең өчен бу – көтелмәгән хәл. Үзебезгә карата шундый игътибар күреп гаҗәпләндек хәтта. Варя татар телен өйрәнергә хыяллана. Әлегә укытыр кеше юк, әмма киләчәктә ул үзе булса да өйрәнер дип уйлыйм. Аңа телләр җиңел бирелә, – диде Олеся Василова.

«ШАЯН ТВ» башкарма директоры, баш мөхәррире Рамилә Сәхабетдинова сүзләренә караганда, телеканал балаларны бәйрәмдә беренче ел гына сөендерми.

– Ел саен балаларыбызның «ШАЯН ТВ»ны күрәселәре килә. Аларның бу хыялын ишетү, аларны үзебезнең студиядә күрү – безнең өчен зур бәхет. Бүген Варвара исемле бик ачык, мөлаем, күңелле кыз белән таныштык. Ул телевидение дигән серле дөнья белән кызыксына, безгә бик күп сораулар әзерләп килгән. Андый балалар белән танышу эшебезнең уңышын да күрсәтә һәм без тагын да рәхәтләнеп эшлибез. Варвара «ШАЯН ТВ»га килергә, безнең белән хезмәттәшлек итәргә тели әнә. Киләчәктә да каналыбыз барлык балалар өчен ачык булыр дип ышанам, – диде Рамилә Сәхабетдинова.

Ләйсән САФИНА

БЕРӘҮ ДӘ ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛ

Очрашудан соң

2024 елда социаль тармакта ниләр үзгәрер? Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова, елга нәтиҗә ясап, журналистлар белән очрашуда шул хакта сөйләде.

Министр әйтүенчә, киләсе ел башыннан минималь хезмәт хакы, яшәү минимумы арта. Узып баручы елда республикада фәкыйрьлек дәрәҗәсе кимегән. Өлкән яшьтәгеләрне яңадан укытып, керемнәрен арттыру мөмкинлеге биргәннәр.

– Республикада уртача хезмәт хакы 59 мең 223 сум тәшкил итә. Татарстан хезмәт хакын түләү буенча Идел буе федераль округында алдынгылыкта, – ди Эльмира Зарипова. – 2024 елда Татарстанда бюджеттан тыш сектор өчен минималь хезмәт хакы күләме 22 мең 20 сум тәшкил итәчәк. Бу – минималь куллану бюджеты кадәр. Без беренче тапкыр республикада минималь хезмәт хакы белән минималь куллану бюджетын тигезли алдык.

Министр яшәү минимумы артачагын да әйтте. Ел башыннан ул 13 мең 135 сум булачак. Фәкыйрьлек дәрәҗәсе исә 2017 елда 7,2 процентны тәшкил итсә, быел 5,5 процентка калган. Ярлылыкны киметүнең төп сәбәбе – социаль контракт, ди Эльмира Зарипова.

– Социаль ярдәм чаралары алучылар саны буенча без аз керемле кешеләрнең кимүен күрәбез. Димәк, кешеләрнең яшәү шартлары яхшыра. Фәкыйрьлектән чыгу өчен төзелгән социаль контракт саны 2015 елда 9 процентны тәшкил итсә, 2023 елда ул 82 процентка җитте. Быел 5216 кеше, социаль контракт төзеп, керемен арттырды, – ди министр.

Кемдер шәхси хуҗалыкта эшли, машина тәзәтү станцияләре ачалар, тегү цехларын эшләтеп җибәрәләр. Мондый кешеләр үзләрен генә фәкыйрьлектән коткарып калмый, башкаларны да эшле итә.

Министр булшай башка һөнәргә укытуга да тукталды. «Демография» илкүләм проекты кысасында 2023 елда 8400 кеше өстәмә һөнәри белем алган. Алар арасында 50 яшькә җиткән 2330 кеше бар. Декрет ялында утырган әниләргә дә икенче һөнәр алу мөмкинлеге тудырыла. Баласына өч яшь тулмаган 3356 кеше, төрле һөнәрләргә булшай укып, эш урынын алыштырган. Министр әйтүенчә, өстәмә белем алу өчен иң популяр юнәлешләргә IT, программалаштыру, менеджмент, маркетплейслар, дизайн юнәлеше кергән.

Министр республикада эшсезләр саны кимүне дә әйтте. Баксаң, эшсез дип теркәлгән 4900 кеше бар, ә эш урыннары 54 меңгә җитә.

Очрашуда Эльмира Зарипова инвалидларга күрсәтелгән ярдәм турында да сөйләде. Аеруча аларны тормышка өйрәтүгә тукталды.

Өйрәнү дигәннән, «Демография» илкүләм проектының «Озак вакытлы карау системасы» программасы кысасында кеше ярдәменә мохтаҗ булган авыруны тәрбияләү буенча да белгечләр әзерләнгәннәр. Дәүләт өлкәннәргә бу кешеләрне бушлай билгели. Ягъни сиделка хезмәтен тәкъдим итә. Шулай ук үз якынын үзе тәрбияләргә теләүче кешеләргә дә бушлай өйрәтәләр.

Журналистлар министрның абортларны тыю буенча нинди фикердә булуын белеште.

– Без тыю мөмкин түгел икәнне аңлыйбыз. Шәхси клиниканың аборт ясарга лицензиясе бар икән, операция уздырыр өчен шартлар тудырылса, берәү дә абортны тыя алмый. Әмма аны һәр хатын-кыз үзе хәл итәргә тиеш, – ди ул. – Баланы төшертү кайбер очракта медицина күрсәткечләре буенча таләп ителсә, кайчакта баланы калдыру-калдырмауны хатын-кыз үзе хәл итә. Ә безнең бурыч – аларны тыңлау һәм ярдәм итү. Бу адым уйланылып эшләнергә тиеш. Яшьлектә баланы төшерел, аннан инде бик табасы килсә дә, алып кайта алмаучы ханымнар бар бит, – ди министр.

Аның фикеренчә, абортка килгән хатын-кызларга хастаханәләрдә, уйлар өчен, бер атна вакыт бирелә. Шул вакытта алар белән белгечләр эшли.

– Бу вакытта министрлык вәкилләре гаиләнең матди хәлен тикшерә. Авыр хәлдә яшәүчеләр булса, сәбәпләрен барлый һәм дәүләттән ничек ярдәм итәргә мөмкин булуын ачыклый. Без бала табарга җыенган хатын-кызга дәүләттән булган ярдәм һәм ташламалар турында да аңлатырга тиеш, – ди ул. – Баланың әтисе белән дә сөйләшергә кирәк. Кайбер очракларда ирләр хатынының балага узганын белми дә кала.

Очрашуда махсус хәрби операциядә катнашучылар да искә алынды. Министр аларның гаиләләренә булган ярдәм чаралары хакында да сөйләде. Киләсе ел башыннан яраланып, имгәнеп кайтучыларны «Идел»дә тернәкләндерә башлаячаклар.

– Алар һәрьяклап ярдәмгә мохтаҗ. Мондагы тормышка ияләшү өчен психолог ярдәме да кирәк булачак. Кешеләр кайчан, кая мөрәҗәгать итәсен белә. Бу – системага салынган эш. Шуңа күрә без ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне алдан белеп торабыз һәм аларга булышабыз, – ди министр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белдерү

Иҗтимагый палата Советы хәбәр итә

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының ике әгъзасы үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы турында» 27 апрель, 2017 ел, № 24-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Советы Иҗтимагый палата әгъзалыгына кандидатларны тәкъдим итүнең башлануы турында хәбәр итә.

Иҗтимагый палата әгъзалыгына кандидат (аны Татарстан Республикасы Рәисе раслый) тәкъдим итү хокукына Татарстан территориясендә теркәлгән гомумроссия һәм төбәкара иҗтимагый берләшмәләрнең структур подразделениеләре ия.

Шулай ук Татарстан территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләрнең дә Иҗтимагый палата әгъзалыгына кандидат (аны Татарстан Республикасы Рәисе раслый) тәкъдим итү хокукы бар.

Гаризаларны кабул итү срогы – бу хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән башлап 30 (утыз) көн эчендә.

Бу җәһәттән тәфсиллерәк мәгълүматлар, кандидатлар өчен документлар формалары Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы сайтына (https://oprt.tatarstan.ru/dokumenti.htm) «Документлар» бүлегенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Администрациясендә гаризалар кабул ителә: **эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә. Төшке аш вакыты: 11.30 сәгатьтән 12.30 сәгатькәчә.**

Кабул итү урыны: Казан ш., Кремль, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе, Татарстан Республикасы Рәисенең гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе.

Документларны почта аша җибәрү өчен адрес: **420111, Казан ш., Кремль.**

Белешмәләр алу өчен телефон: **8(843) 567-88-92.**

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасында гаризалар кабул ителә: эш көннәрендә **09.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә. Төшке аш вакыты: 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә.**

Кабул итү урыны: «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесе, 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 А й., 133 б.

Документларны почта аша җибәрү өчен адрес: **420111, Казан ш., Батурин ур., 7 А й.**

Белешмәләр алу өчен телефоннар: **8(843) 567-80-96, 567-80-99.**

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНДА САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, «Россия Федерациясе Президентын сайлау турында» Федераль законның 51, 53 статьялары нигезендә, 2024 елның 17 февраленнән 15 мартның 0.00 сәгатенә кадәрге чорда сайлау алды агитациясен урнаштыру өчен, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясендә теркәлгән дәүләт башлыгы вазыйфасына кандидатларга түләүле нигездә басма мәйдан тәкъдим итә, шулай ук газетада дәүләт башлыгын сайлау буенча агитация материалларын бастыру бәяләрен игълан итә.

Төбәкләрнең дәүләт матбугат басмаларында кандидатларның һәм сәяси партияләрнең язмаларын бушлай урнаштыру законда күздә тотылмаган.

Гомуми түләүле мәйдан атнага бер тапкыр А2 форматында бер бит тәшкил итәчәк. Кандидатларның язмалары чәршәмбе көннәрендә уртак биттә урнаштырылачак. Газета мәйданы кандидатлар арасында тигез бүленә. Һәркайсына күпме урын биреләчәге теркәлгән кандидатлар санына бәйле булачак. Редакция кандидатларга бу хакта соңрак, жирәбә үткәрү барышында, өстәмә рәвештә хәбәр итәчәк.

Заказчының теләгенә карап, индивидуаль квота кысасында, газетаның башка саннарында да язмалар урнаштырырга мөмкин.

Редколлегия сайлау алды кампаниясендә катнашучыларның барчасы өчен бердәм бәяләрне раслады. Россия Федерациясе Президентын сайлау буенча түләүле мәйданның минималь бәясе бер квадрат сантиметр өчен 100 сум тәшкил итәчәк (сайлау көне якынлашуга карап, бәя арта). Алдан түләп куйганлыкка (йөз процент) документ, язма басылып чыгарга кимендә өч көн кала, кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырыла.

1. Төп тариф:

А2 форматындагы газетаның бер бите (сишәмбе, чәршәмбе саннары): 17–23 февраль чорында – 158 мең 400 сум; 24 февраль – 1 март чорында – 208 мең 400 сум; 2–8 март чорында – 258 мең 400 сум; 9–14 март чорында – 308 мең 400 сум;

А3 форматындагы бер бит (җомга саны):
17–23 февраль чорында – 143 мең 100 сум; 24 февраль – 1 март чорында – 193 мең 100 сум; 2–8 март чорында – 243 мең 100 сум; 9–14 март чорында – 293 мең 100 сум.

2. Өстәмә бәя:

А2 форматындагы газетаның беренче битендә бастыру өчен (мәйданы – битнең күп дигәндә 1/8 өлеше) – югарыда телгә алып үтелгән бәянең 100 проценты; биттә урын сайлау өчен (беренче, икенче биттән тыш, шулай ук җомга санының өченче битеннән тыш) – 50 процент.

Бәяләр НДСны кертеп күрсәтелә.

Барлык агитация материалларында язма өчен кайсы кандидатның сайлау фонды акчасы хисабына түләнелүе турында мәгълүмат булырга тиеш. Вакытында тапшырылмаган яки сайлау турында законга туры килмәгән материаллар кире кайтарыла.

Түләүле басма мәйдан бирүгә жирәбә үткәрү вакыты турында, шулай ук агитация язмаларының графигы турында өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

Редакция телефоны: (843) 222-09-70. Электрон почта адреслары: info@vatantat.ru, husnullah81@mail.ru.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

2023 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

2023 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты» исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. 6 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1998–2021 еллар) хезмәте өчен:

Тимерханов Айнур Әхәт улына, филология фәннәре докторы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе вице-президенты, мөхбир-әгъзасы, хезмәтнең җитәкчесенә;

Галимова Ольга Николаевнага, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәренә;

Гаффарова Фирая Фаяз кызына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлегенең элеккеге өлкән фәнни хезмәткәренә;

Сабирова Гөлзадә Гарәфетдин кызына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлегенең элеккеге өлкән фәнни хезмәткәренә;

Сабитова Илһамия Исламетдин кызына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәренә;

Сәфәров Ринат Таһир улына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәренә;

Сафина Эльвира Ирфат кызына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәренә;

Таһирова Фәридә Инсан кызына, филология фәннәре кандидаты, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең лексикография бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәренә.

2. «Сугарылган җирләрдә иген игүнең Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы производствосы икътисадый нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итә торган инновацияле алымнарын эшләү һәм кулланышка кертү» хезмәте өчен:

Хисмәтуллин Марс Мансур улына, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, доцент, «Идел буе федераль округы буенча җирләрне сугару һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе директоры, хезмәтнең җитәкчесенә;

Вәлиев Айрат Рәсим улына, техник фәннәр докторы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе мөхбир-әгъзасы, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорына;

Вафин Радик Кадыйр улына, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгына, Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы;

Миңнуллин Генадий Сәмигулла улына, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгына, Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы;

Сөләйманов Салават Рәҗәп улына, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, доцент, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең җир төзелеше һәм кадастрлар кафедрасы мөдиренә;

Сөнгатуллин Рөстәм Хизбулла улына, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директорына;

Хисмәтуллин Марсель Мансур улына, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең авыл хуҗалыгы производствосын оештыру кафедрасы доцентына.

3. «Ми-38 күпмаксатлы вертолетын серияле җитештерүгә кую» хезмәте өчен:

Бугаков Игорь Сергеевичка, техник фәннәр кандидаты, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең конструкторлык-технология үзәгенең элеккеге директоры, хезмәтнең җитәкчесенә;

Аменова Карлыгаш Ормановнага, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең цех башлыгына;

Әхмәтҗанов Виктор Хәерҗан улына, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең элеккеге цех башлыгына (вафатыннан соң);

Коробов Сергей Яковлевичка, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте баш технологының элеккеге урынбасарына;

Лаврентьев Александр Петровичка, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесенә;

Павлов Леонид Николаевичка, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте техник директорының элеккеге беренче урынбасары, баш технологы идарәсе башлыгы, баш технологына (вафатыннан соң);

Пискунов Владимир Георгиевичка, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең автоматлаштырылган идарә системалары бүлеге башлыгына;

Шаргин Вячеслав Павловичка, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең элеккеге баш конструкторы, серияле конструкторлык бүлеге башлыгына.

4. «Комплекслы белешмәләрне җыю һәм эшкәртүне ясалма интеллект ярдәмендә автоматлаштыру системасы булган махсус билгеләнештәге геодезия челтәрен булдыру, төзү һәм аның эшләве» хезмәте өчен:

Сәхәутдинов Рөстәм Вил улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсенең топография-геодезия, мөлкәт, маркшейдерлык эшләре идарәсе башлыгы – баш маркшейдерына, хезмәтнең җитәкчесенә;

Баратов Азиз Рәүф улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан геология-разведка идарәсе геология бүлеге әйдәүче геологына;

Гатиятуллин Рамил Нәкыйп улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан геология-разведка идарәсе башлыгына;

Гыйлаев Дамир Мөнҗил улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсенең топография-геодезия, мөлкәт, маркшейдерлык эшләре идарәсе башлыгы урынбасары – топография-геодезия һәм маркшейдерлык эшләре бүлеге башлыгына;

Җиһаншин Эдуард Ришат улына, геология-минералогия фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты геофизика һәм геомәгълүмат технологияләре кафедрасының беренче категорияле инженерына;

Кузьмин Юрий Олеговичка, физика-математика фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясенең О.Ю. Шмидт исемендәге Җир физикасы институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директорының гамәли геодинамика һәм җаваплы объектларны мониторинглау мәсьәләләре буенча урынбасарына;

Рәхмәтуллин Мәлик Хәмит улына, физика-математика фәннәре кандидаты, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсенең маркшейдер-геодезия төркеме маркшейдер-җир төзелеше үзәгенең элеккеге әйдәүче инженерына;

Яруллин Айрат Данир улына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының «Җир асты резервуарларында углерод диоксидын утильләштерү» лабораториясе кече фәнни хезмәткәренә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 26 декабрь
№ 912

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТӨРЕК

Азнакай

ЯКЫН ИТҮ

Төркия туган җир булса да, Татарстан күңелгә якынрак. Азнакайда үз гаиләсе белән яшәүче Ырмак Каракылыч әнә шулай ди. Биредә ул хатыны Юлия белән өч кыз бала тәрбияләп үстерә. Кызлары – төрек һәм башка телләр буенча республика һәм халыкара олимпиада җиңүчеләре. Гаиләдә дә төп аралашу – төрек телендә. Ләкин шул вакытта башка милләтләрнең телләрен дә, мәдәниятен дә хөрмәт итеп яши Каракылычлар гаиләсе. Чит илдә дә солтан булып яшәү серләрен аларның үзләреннән белештек.

Тырыш һәм гадел милләт

Ырмак Төркиянең Эрзинь шәһәрендә күпбалалы гаиләдә туып-үскән. Татарстанга 1996 елда белем алырга килә. Казан дәүләт педагогика университетын тәмамлагач, бизнес белән шөгыльләнергә теләп, Азнакайга күченә. Хәзерге вакытта Ырмак – эшмәкәр. Терлек сатып алып, ит белән шөгыльләнә, үзләренең кибете бар. Моннан тыш, ул – Азнакайның төрек диаспорасы җитәкчесе.

> Мин инде озак еллар Татарстанда, Азнакайда яшим. Төркияне яратсам да, Азнакай күңелемә якынрак, чөнки монда гаилә кордым, балаларыбыз шушы җирдә туды, эшләрем, йортым биредә. Халкына да ияләштем. Төркиягә барсак та, бер атнадан соң өйгә кайтасы килә башлый.

Гомумән алганда, безнең гаилә Татарстан һәм Төркия традицияләре буенча яши. Барлык җирле бәйрәмнәрне, йолаларны хөрмәт итәбез. Мөмкин булганча, шәһәр һәм район күләмендә узган чараларда катнашырга тырышабыз. Минем өчен беркемне дә милләтенә карап аеру юк. Татарын да, русын да, азәрбайҗанын да хөрмәт итәм. Боларның берсе дә төрек телен, аның мәдәниятен, йола һәм гадәтләрен гаиләмә, балаларыма бирүгә комачауламый, – ди ул.

Бәлки нәкъ менә шундый карашы аркасында ул тормышын Юлия белән бәйләргә булгандыр да.

– Безне уртак танышлар таныштырды, – диде Юлия, Ырмак белән танышу тарихын искә алып. – Мин үзем – Татарстаннан, Яшел Үзәннән. Катнаш гаиләдә туып-үстем. Әтием – рус, әнием – татар. Башта әти-әнием Ырмакны ничек кабул итәр икән, дигән курку һәм шикләнү бар иде. Ләкин аның белән танышкач, сайлаган ярымның өлкәннәргә карата булган хөрмәтен, уңай мөнәсәбәтен күргәч, шунда ук фатиха бирделәр.

Юлия әйтүенчә, төрекләрнең башкалардан аерылып торган сыйфатлары: өлкәннәргә, балаларга һәм хатын-кызларга булган хөрмәте.

– Ырмакның әтисе яшьли вафат булу сәбәпле, ул – гаиләдәге өч энесе өчен абруйлы кеше. Аңа хөрмәт бик зур. Моннан тыш, төрекләр – бик бердәм һәм кунакчыл милләт. Тырыш, уңган булуларын да әйтми булдыра алмыйм. Алар гаиләләре иминлеге өчен көнтөн эшләргә риза. Боларга гадел һәм җаваплы булуларын да өстәргә кирәк, – ди ул.

«Тел белүләре мөһим»

Гаиләдә ике төрле менталитет булса да, төп кагыйдәләр Ырмак күзлегеннән карап кабул ителгән.

– Без икебез дә гап-гади, урта хәлле гаиләдән. Ә инде бергәләп күтәрелү, матур тормыш кору безнең максатыбыз иде. Һәм без моңа ирешә алдык. Ләкин шул ук вакытта баштагы елларда икебезнең ике төрле менталитеты уртак тормышта үзен еш сиздерде. Әле аңа, әле миңа баш бирергә туры килде. Хәзер инде без алтын урталыкны таптык дип әйтә алам. Кайдадыр ул – миңа, кайдадыр мин аңа җайлаштым. Безнең гаиләдә, һичшиксез, ирем – баш. Балаларның да төрекчә бик әйбәт белүләрендә әтиләренең роле зур. Моннан тыш, алар татарча, русча һәм инглизчә иркен аралашалар. Азнакайда яшәгәч, татар телен дә белүләре кирәк, чөнки биредә бөтен кеше татарча сөйләшә. Һәм бу безгә бик ошый, – ди Юлия Каракылыч.

Балаларына исем сайлаганда да барысын да исәпкә алырга туры килгән.

– Мин балаларыма бары тик төрек исемнәре генә бирергә теләдем, ләкин шул ук вакытта аларның башка кешеләргә әйтергә уңайлы булуын да истә тоттым. Ничек кенә булса да, без бит Татарстанда, күп төрле милләт вәкилләре арасында яшибез. Шуны истә тотып, олы кызыбызга Алейна, икенчесенә Сафия, өченчесенә Элифнур дигән исемнәр бирдек, – ди гаилә башлыгы.

Тел саклау кебек зур миссияне дә Ырмак бик лаеклы башкара дип аңладык. Кызлар белән шөгыльләнү – аның җаваплыгында.

– Әйе, мин үзем өйдә булганда, балалар белән төрекчә генә аралашам.

> Кызларыбызның үз туган телләрен белүләре минем өчен мөһим. Көндәлек тормышта төрекчә, татарча һәм русча аралашсалар да, 6 яшькә кадәр төрек теле белән ныклап торып шөгыльләнмәдем. Чөнки телләренең акцентларсыз, чиста ачылуын теләдем. Бары тик 6 яшьләре тулып узгач кына, төрек дәресләре бирә башладым. Балаларыбыз – төрек һәм алар моның белән чынлап торып горурлана, – ди Ырмак.

– Билгеле бер милләт вәкиле булу – телне генә белү дигән сүз түгел ул, – дип ассызыклады Юлия. – Бу турыда олы кызыбыз белән еш сөйләшәбез. Аларга төрекләрнең мәдәнияте, менталитеты, бәйрәмнәре дә кызыклы.

Әйтергә кирәк, Юлия белән Ырмакның кызлары бик актив. Җырлыйлар, бииләр, күптөрле республика һәм халыкара олимпиада җиңүчеләре. Әлеге вакытта өлкән кызлары Казанның 4 нче гимназиясендә белем ала, төпчекләре Элифнурга – 8 яшь.

Елау – бәхеткә

Ырмак белән Юлиянең туйлары гап-гади, ягъни без күреп белгәнчә заманча узган. Өч көн ашап-эчеп, җырлап-биеп бәйрәм итү дә булмаган аларда. Хәер, Ырмак әйтүенчә, хәзер инде Төркиядә дә йолалар кечкенә авылларда гына сакланып калган.

– Безнең чын төрек туйларында катнашканыбыз булды. Аларда «кына киче» дигән йола башкарыла. Бу кичне кәләшнең кулларын кына белән бизиләр һәм янында күңелсез, елата торган җырлар җырлыйлар. Ара-тирә кәләшнең елау-еламавын да тикшерәләр. Бу кичне кыз бала никадәр күбрәк еласа, шуның кадәрле бәхетле булачак, дигән ышану бар, – ди Юлия.

Төркиягә Ырмакның туганнарына кунакка баргач, андагы яшәү рәвешен күзәтергә, төрекләр белән аралашырга ярата Юлия.

– Төрек хатыны тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бик күп бизәнгечләр тагып йөри. Аш-су бүлмәсендә камыр изгәндә дә кулларындагы алтын беләзекләрен салмый алар. Туй алдыннан ике як гаилә, кара-каршы

утырып, яшьләргә нинди бүләк бирәсен хәл итә. Мәсәлән, кияү кәләшкә билгеле бер күләмдә алтын бүләк итсә, кәләш ягы яшьләрнең йортына җиһазлар алып бирә. Гаилә таркалган очракта исә, хатын-кыз үзе белән бүләккә бирелгән барлык алтын эшләнмәләрне алып китә ала. Ә мин үзем алтын әйберләр тагарга яратмыйм, шуңа күрә Ырмактан сораганым да юк, – дип елмая Юлия.

Каракылыч гаиләсеннән икехатынлылык кебек күренеш турында да кызыксындык.

– Безнең нәселдә андый нәрсә юк. Шуңа күрә минем бу хакта уйлап та караганым юк, – дип җавап бирде Ырмак. – Кызларымны да бары тик төрек милләтеннән генә булган кешеләргә кияүгә бирү теләгем юк. Иң мөһиме – яхшы һәм динле кеше булсыннар.

Милли ризык

Долма

Төрекләр дөге, кузаклы үсемлекләр яратып кулллана. Ә менә бәрәңгене бик сирәк ашыйлар. Шулай да төрек хатыннарының иң яратып әзерли торган ризыклары – долма. Юлия ханым аны пешерү серләре белән бүлеште.

Зур булмаган кәстрүл төбенә бераз май салабыз, аның өстенә долманы (ит һәм дөгене виноград яфрагына төреп ясала) тыгызлап урнаштырабыз. Түменчә тозлыйбыз (тик ул күп булмаска тиеш), өстенә зәйтүн мае салырга мөмкин. Шуннан соң долма кәстрүлдә йөзеп йөрмәсен, ә яхшылап томаланып пешсен өчен, тәлинкә белән бастырып куябыз да өстенә бераз су агызабыз. Кайнап чыккач, 40 минут чамасы сүрән утта пешереп бетерәбез.

Табынга лимон согы сыгып, каймак белән бирәбез.

УРТАК КАЗНА

Төрекләрнең бик матур бер гадәтләре бар икән. Ул изге рамазан ае узгач башкарыла.

– Бу йола мине таң калдырды, – ди Юлия. – Ел саен рамазан ае узуга, туганнар җыелыша. Шундый бер чарада минем дә катнашканым булды. Ул вакытта Ырмакның әнисе ягыннан гына да йөзләп кеше җыелган иде. Күрешү, аралашу, яңа туганнар белән танышу булды ул. Барлык туганнар арасында иң өлкән, авторитетлы өч абый бар. Алар үз исемнәренә банкта махсус счет ачалар. Һәм һәр ел саен менә шундый туганнар очрашуында кем никадәрле булдыра, шуның кадәрле акчаны абыйларга бирә. Һәм әлеге акча махсус счетка салына. Әгәр нәселдәге берәр кешегә яки гаиләгә бәла-каза килә, яки җитди авырулар белән авырый башлыйлар икән, яки туйлар уздырырга мөмкинлекләре җитеп бетми икән, җыелган акча шушы кешегә ярдәм йөзеннән бирелә. Әйтик, Төркиядәге бик көчле җир тетрәү вакытында Ырмакның туганнары да зур зыян күрде. Счеттагы акча әлеге гаиләләргә ярдәм итүгә тотылды. Ул фаҗига вакытында туганлык көчләре аеруча нык сизелде.

Күркәм гадәтләр

- Өлкән яшьтәге әти-әниләр бервакытта да ялгызлары гына яшәми. Аларны яки балалары үз яннарына алып китә, яки берәр баласының гаиләсе өлкәннәр янына күченә.
- Төркиянең зур булмаган шәһәрләрендә яшәүчеләр бер-берләрен яхшы белә. Әгәр кем дә булса бакыйлыкка күчсә, җеназага дәшеп, мәчетләрдән азан яңгырый. Моннан тыш, мәрхүмне озатырга җыелган халыкны хәлвә белән сыйлау гадәте бар.
- Баланы сөннәткә утырткан көнне туганнарны җыеп, зур бәйрәм – сөннәт туе ясыйлар. Малайны матур итеп киендерәләр. Моның өчен махсус кием сатып алына яки тегелә. Кунаклар исә күп бүләкләр белән килә.

Сәхифәне Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 371

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+